ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 февраль, 2016 ел № 6/9

«2030 елга кадәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе» проекты буенча гавами тыңлаулар хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсе, шәһәр Уставының 19, 28 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. «2030 елга кадәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе» проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү көнен 2016 елның 10 мартына, үткәрү вакытын 14 сәгатькә тәгаенләргә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.
2. «2030 елга кадәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе» проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү буенча комиссия составын кушымтадагыча расларга.
3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БУЛЕГЕ

Шәһәр Советы Карарына
кушымта
24 февраль, 2016 ел

«2030 елга кадәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе» проекты буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Кропотова Наталия Анатольевна | - Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әдһәмова Лилия Шәүкәт кызы | - шәһәр Хакиме (Шәһәр Советы) аппаратының оештыру-аналитик һәм хокукый эшләр идарәсе башлыгы, проектны эшләү буенча эшче төркем әгъзасы; |
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | - Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының хокук идарәсе башлыгы; |
| Воронина Елена Васильевна | - Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, проектны эшләү буенча эшче төркем әгъзасы; |
| Ганиев Мәхмүт Мәсгуть улы | - Казан (Идел буе) федераль университетының Яр Чаллы институты директоры, проектны эшләү буенча эшче төркем әгъзасы (килешү буенча); |
| Камалетдинова Ләлә Әнвәр кызы | - Шәһәр Советы депутаты, гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе, проектны эшләү буенча эшче төркем әгъзасы; |
| Королева Екатерина Александровна | - Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының икътисадый үсеш һәм |

| | |
|---|---|
| | эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе баш белгече; |
| Савельев Игорь Николаевич | - «КАМАЗ» ААҖнең Стратегик планлаштыру хезмәте җитәкчесе, проектны эшләү буенча эшче төркем әгъзасы (килешү буенча); |
| Туктарова Венера Надир кызы | - Шәһәр Советы депутаты, социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссия рәисе. |